устный опрос , примерные вопросы:

1. Кече тел тартыклары гына булган рәтне билгеләгез. а) [д], [т], [с]; ә) [б], [п], [м]; б) [ф], [в]; в) [ҡ], [ғ], [ң]. 2. Ирен гармониясенә буйсынган сүзләр рәтен билгеләгез. а) көндез, бөек; ә) салкын, такыр; б) бара, кайта; в) тыныч, дымлы. 3. Үсемлекләрнең сүзенең мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленешен күрсәтегез. а) ү-сем-лек-ләр-нең; ә) үсем-лек-ләр-нең; б) үс-ем-лек-ләр-нең; в) үс-емлек-ләр-нең. 4. Авазларның позицион үзгәрешләре ничек барлыкка килә? а) авазларның янәшә торуы аркасында барлыкка килә; ә) авазларның бер-берсенә тәэсир итүе нәтиҗәсендә туа; б) авазның сүздәге урынына һәм басымга бәйле була; в) авазларның бер-берсенә охшашлануына нигезләнә. 5. Семасиология фәне - а) сүзләрнең мәгънәсен, мәгънәләр үсешен-үзгәрешен өйрәнә; ә) телдәге бер төшенчә белдерү өчен катып калган тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәнә; б) лексиканың үсешен, телнең сүзлек составын һәм аның яшәешен өйрәнә; в) ялгызлык характерындагы географик атамаларны өйрәнә. 6. Бу сүзләр татар теленә кайсы телдән кергән? Арыш, сука, салам, эскерт, кәбестә, бүрәнә а) гарәп теленнән; ә) рус теленнән; б) фарсы теленнән; в) грек теленнән. 7. Бер төрдән булган предметларның берсен икенчесеннән аеру өчен бирелгән исемнәр а) конкрет; ә) уртаклык; б) ялгызлык; в) абстракт исем дип йөртеләләр. 8. ?Яз кайтмасам, көз кайтам дип, үз күңелемне юатам? җөмләсендәге калын хәрефләр белән бирелгән баш килештәге исемнәр а) ия; ә) тәмамлык; б) хәл; в) аергыч функциясендә килгән. 9. Яраттым мин хаклык, дөреслекне, Ялган белән сүзем төрмәдем. (Ш. Мөдәррис) Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр җөмләнең кайсы кисәге? а) исемнәр; ә) тәмамлыклар; б) ияләр; в) аергычлар. 10. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез. Мин елмаеп кына, дөнья үзгәрерме, Шундый сорау бәргәләнә җанда.(Р.Низами) а) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә; ә) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә; б) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә; в) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

**Тема 5. Алмашлыкларның, кисәкчәләрнең дөрес язылышы**

мөстәкыйль эш , примерные вопросы:

1. Барлык сүзләрдә дә һ хәрефе языла торган сүзләр рәтен билгеләгез. а) да..и, мәш..үр, ..әлак; ә) ..өкем, ..өнәр,..өҗүм; б) мә..әббәт, а..әң, ил..ам; в) ..ыял, зин..ар, пө..тә. 2. Җөмләдә кайсы сүздә редукция күзәтелә? Син минем бәхетем идең. (М.Мәһдиев) а) син; ә) минем; б) бәхетем; в) идең. 3. Боргаланалар сүзенең мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленешен күрсәтегез. а) бор-га-ла-на-лар; ә) бор-галан-а-лар; б) бор-гала-н-а-лар; в) бор-га-лан-а-лар. 4. Телләрне кардәшлек ягыннан төркемләү ? а) телләрнең таралышын билгеләү; ә) телләрне гаиләләргә берләштерү; б) телләрне дөньякүләм дәрәҗәләренә карап бүлү; в) телләрне типларга аеру. 5. Идеографик язудан хәзерге көндә кайсы халык файдалана? а) япон; ә) кытай; б) гарәп; в) латин. 6. ?Тәлинкә тотучы? фразеологизмының мәгънәсен күрсәтегез а) авыру кеше; ә) ашыйсы килгән кеше; б) тәлинкә юучы кеше; в) ялагай кеше. 7. Аның, аңа, аны, анннан, анда. Нинди алмашлык килеш белән төрләнгән? а) бу алмашлыгы; ә) ул алмашлыгы; б) шул алмашлыгы; в) теге алмашлыгы. 8. Асыл сыйфатлар төркемен билгеләгез. а) тар, җәйге, апанықы, җиңел; ә) аскы, эссе, йомшак, каты; б) кечкенә, тәмле, саф, шаян; в) язгы, кышкы, кичке, яңа. 9. Җөмләнең иярчен кисәкләре: а) аергыч, тәмамлык, хәл, аныклагыч, эндәш сүз, кереш сүз; ә) аергыч, тәмамлык, хәл, аныклагыч; б) ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык, хәл; в) аергыч, тәмамлык, хәл. 10. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез. Буран чыкса, көрт басар дип, әнкәй капкасын да ачык калдырган. (М.Галиев) а) берничә төр ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә; ә) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә; б) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә; в) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

**Тема 6. Хикәя фигыль кушымчаларының дөрес язылышы**

рефератлар тыңлау , примерные темы:

1. Татарларда гарәп алфавиты кайсы гасырларда кулланылган? а) X - XVIII гасырларда; ә) X - XX гасырларда; б) X - XXI гасырларда; в) X - XIX гасырларда. 2. Тормыш, өлгер, озак, төлке, кояш, өмет, болытлы, йөгерек сүзләренең ирен гармониясенә буйсынуы түбәндәгечә: а) бер сүздә ирен гармониясе күзәтелми; ә) ике сүздә ирен гармониясе күзәтелми; б) өч сүздә ирен гармониясе күзәтелми; в) барлык сүзләрдә дә ирен гармониясе күзәтелә. 3. Кул-аяк җитмәү фразеологизмының мәгънәсе: а) бөтен эшкә өлгерү; ә) теләсә нинди эшкә катнашып йөрү; б) эшне тиз башкарып чыгу; в) уйлаган эшеңне эшләргә җитешмәү. 4. Этимология ул - ... а) ялгызлык исемнәрне өйрәнә; ә) телнең тотрыклы сүзтезмәләрен өйрәнә; б) сүзнең килеп чыгышын өйрәнә; в) сүзләрнең мәгънәсен өйрәнә. 5. Мөнәсәбәт белдерүче модальлек кушымчалары гына булган рәтне билгеләгез. а) -ды/-де, -сыз/-сез, -чы/-че; ә) -рак/-рәк, -кай/-кәй, -шар/-шәр; б) -лар/-ләр, -ган/-гән, -да/-дә; в) -са/-сә, -ып/-еп, -ачак/-әчәк. 6. ашлык, елъязма, авылдаш, егет-җилән, кыз-кыркын, үзбушаткыч, чаңгычы, сукыр кычыткан сүзләре арасында ясалма сүзләр: а) 2; ә) 4; б) 6; в) 8. 7. Кояш үз юлы белән әкрен генә төшеп бара (И.Г.) җөмләсендә бара сүзе: а) мөстәкыйль фигыль; ә) ярдәмче фигыль; б) ярдәмче фигыль функциясендә килгән мөстәкыйль фигыль; в) мөстәкыйль фигыль функциясендә килгән ярдәмче фигыль. 8. Никадәр генә биек менгән булсалар да, моңлы җырлары әле һаман җиргә төшеп җитә: челтер-челтер, туррый-туррый, яй-яй (И.Г.) җөмләсендә билгеләнгән сүзләр: а) ымлыклар; ә) модаль сүзләр; б) аваз ияртемнәре; в) кисәкчәләр. 9. Җөмләнең төрен билгеләргә. Ләкин адәм баласына шул нәрсә хас: ул, үзе чибәр булмаса да, чибәр булырга омтыла (В.Нуруллин). а) тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә; ә) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә; б) берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмлә; в) бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә 10. Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез. Күзләремне йомып кына алсам да, тургай инде югалачак (И.Г.) а) иярчен вакыт җөмлә; ә) иярчен шарт җөмлә; б) иярчен кире җөмлә; в) иярчен сәбәп җөмлә.

**Тема 7. Орфографик кагыйдәләрне өйрәнүнең грамоталылыкны күтәрүдәге роле**

кагыйдәләрне кабатлау, сорауларга җавап бирү, практик өлешендәге биремнәргә якынча мисаллар башкару , примерные вопросы:


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

1. Кайсы сүздә ?э? хәрефе бугаз тартыгы һәмзә [,] авазын белдерә? а) маэстро; ә) тәэсир; б) дуэль; в) аэродром. 2. Билгеләнгән сүзләр нәрсә була? Ябалак кар яуган төсле, Яфрак ява кыштыр-кыштыр. Гүя урман икеләнә: ?Көз түгелдер, кыштыр, кыштыр?. а) омофон; ә) омограф; б) омоформа; в) саф лексик омоним. 3. Мөнәсәбәт белдерүче модальлек кушымчаларыннан гына торган төркемне билгеләгез. а) -гач/-гәч, -ачак/-әчәк, -ның/-нең, -ыл/-ел/-л; ә) -ды/-де, -тыр/-тер, -ынчы/-енче, -сыл/-сел; б) -рак/-рәк, -ып/-еп, -лар/-ләр, -ым/-ем/-м; в) -са/-сә, -ырга/-ергә, -ма/-мә, -ганчы/-гәнче. 4. Билгеле бер телдәге сүзләр җыелмасын ничек атыйлар? а) лексикография ә) лексикология б) лексика в) лексема 5. ?да ? дә кушылып язылган җөмләләрне билгеләгез. а) Сыртың сынса (да), сереңне бирмә (М.). ә) Үзе суга ? авырттырмый (да), канатмый (да) (Т). б) Көн-төн йөри ? армый (да), талмый (да) (Т). в) Көндез ? хөрмәт (тә), кич ? хезмәт (тә) (Т). 6. Көтү кайтканны күзәтү күңелле. Үлчәү тәлинкәсенең формасы төрле булырга мөмкин. Җылы сөяк сындырмый, салкын җанны тындырмый (М.) җөмләләрендәге билгеләнгән сүзләрнең ясалыш ысулы а) сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү; ә) сүзләрнең аваз составы үзгәрү; б) сүзләрнең бер сүз төркеменнән икенчесенә күчүе; в) сүзләр кушылу. 7. Бәйлек сүз кергән җөмләне табыгыз. а) Болытлар өстендә бер тургай сайрый. ә) Өйгә чаклы бер сүз дә сөйләшмичә кайттык. б) Яныңа үзем киләм. в) Сиңа ярдәм итү өчен тырыштым. 8. ?Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел? мәкалендәге билгеләнгән сүзләргә кайсы билгеләмә туры килә? а) билгесез үткән заман хикәя фигыль; ә) үткән заман сыйфат фигыль; б) исемләшкән үткән заман сыйфат фигыль; в) билгесез үткән заман сыйфат фигыль. 9. Билгеләнгән сүз нинди җөмлә кисәге? Күргәзмәдә катнашучыларга рәсем бик ошады. а) ия; ә) хәл; б) тәмамлык; в) аергыч. 10. Җөмләнең төрен билгеләргә. Кояш чыга койма аръягында, Күрше кырлар нурга коена. Тик, нигәдер, аның нуры безгә Тими үткән кебек тоела. (М.Җәлил.) а) күп иярченле кушма җөмлә; ә) күп тезмәле кушма җөмлә; б) катнаш кушма җөмлә; в) иярченле кушма җөмлә.

**Тема 8. Пунктуация. Тыныш билгеләрен куллану тарихы**

устный опрос , примерные вопросы:

1. ?Казан кара булса да, барын да туйдыра? мәкалендәге сузыкларга нинди билге уртак? а) барысы да чагыштырмача кыска; ә) барысы да нечкә; б) барысы да чагыштырмача озын; в) барысы да калын. 2. Кайсы мәкальдә рәт гармониясенә буйсынмаган сүз бар? а) ?Кырык өйдән кырык бер сохари?; ә) ?Язның бер көне ел туйдыра?; б) ?Күршеләргә туй килсә, син дә капкаң ачып куй?; в) ?Эш беткәч, уйнарга ярый?. 3. Коръән сүзендә ъ билгесе нинди функция башкара? а) аеру билгесе буларак кулланыла; ә) [һәмзә] авазын белдереп килә; б) иҗекнең калын әйтелешен тәэмин итә; в) дөрес җавап бирелмәгән 4. Ясалма сүзләрдән генә торган рәтне табыгыз. а) яшел, төркем, тамыр; ә) җирдәге, торак, сугыш; б) көрәк, замана, бушлай; в) үзгәреш, тантана, көлмәк. 5. Кайсы сүз тамыр, сүз ясагыч, һәм бәйләгеч кушымчалардан тора? а) яшьлеккә; ә) кошчыкны; б) әткәйгә; в) урамдагы. 6. [җ] авазына дөрес билгеләмә кайсы төркемдә бирелгән? а) тел алды, парлы, саңгырау аваз; ә) тел уртасы, парсыз, яңгырау аваз; б) ирен-ирен, парлы, саңгырау аваз; в) тел алды, парлы, яңгырау аваз. 7. Билгеләнгән сүзнең нинди җөмлә кисәге булуын билгеләгез. Укытучымның әйткән киңәшләрен һәрвакыт исемдә тотарга тырышам. а) тәмамлык; ә) аергыч; б) хәл; в) дөрес җавап бирелмәгән. 8. Уртаклык юнәлешендәге фигыльләрдән торган рәтне табыгыз. а) тырыш, ялгыш; ә) көмеш, җимеш; б) тормыш, язмыш; в) тикшереш, сөйләш. 9. Фразеологик әйтелмәләр кайсы төркемдә бирелә? а) әни көлмәге, ак каен, җитез җил; ә) бака яфрагы, бәбкә үләне, күгәрчен күзе; б) күз салу, сүзсез калу, баш бирмәү; в) җырлап җибәрү, утырып калу, алып бирү. 10. Бирелгән җөмләнең төрен дөрес билгеләгән рәтне күрсәтегез. Атлар узган сукмакта чабата эзләре генә кала. (Г.Б.) а) иярчен ия җөмләле кушма җөмлә; ә) иярчен хәбәр җөмләле кушма җөмлә; б) иярчен аергыч җөмләле кушма җөмлә; в) иярчен урын җөмләле кушма җөмлә.

**Тема 9. Татар телендә тыныш билгеләре. Аларның функцияләре**

устный опрос , примерные вопросы:

1. Кайсы сүздә 6 аваз бар? а) сәяхәт; ә) язучы; б) ярыш; в) ябалак. 2. Кайсы рәттәге сүзләрдә күпнокталар урынына бер үк хәрефләр языла? а) кө...батыш, ә...кәй, у...биш; ә) г...ди, г...мер, г...дел; б) к...гыйдә, к...ләм, к....рылтай; в) ел...язма, кул...язма, бер...юлы. 3. Хаталы сүзне табыгыз. а) шөгыль; ә) мәкалә; б) гәдел; в) табигать. 4. Мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленмәгән сүзләрне күрсәтегез. а) дус-лар-ча, сигез-енче; ә) ки-ен-гән-сез, зур-рак; б) эш-лә-дек, дәфтәр-ен; в) бәхет-ле-ләр, юл-даш-ка. 5. Конверсия ысулы ул ? а) сүзнең мәгънәсен үзгәртү; ә) сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү; б) сүзләрнең аваз составын үзгәртү; в) кушма сүзләр ясалу. 6. Исемнәрдә күплек сан кушымчалары кайсы төргә карый: а) ясагыгыч кушымча; ә) бәйләгеч кушымча; б) модальлек кушымчасы; в) берсе дә туры килми. 7. Җөмләдәге билгеләнгән сүз нинди сүз төркеме? Безнең бакчада Иделнең иң матур җирендә урнашкан. а) кисәкчә; ә) теркәгеч; б) бәйлек; в) рәвеш. 8. Гомумиләштерүче сүз тиңдәш кисәкләрдән алда килсә а) ике нокта; ә) сызык; б) өтер; в) җәяләр куела. 9. Печән өсте килеп җиткәнне без, малайлар, бик зур дәрт белән көтеп алабыз. (Г.Б.) Бу җөмләдәге килеп җиткәнне сүзе нинди җөмлә кисәге булып килә? а) аергыч; ә) тәмамлык; б) хәбәр; в) хәл. 10. Иярчен җөмләнең мәгънәви төрен билгеләгез. Кулымнан ни килсә, барысын да эшләрмен. а) иярчен хәбәр җөмлә; ә) иярчен тәмамлык җөмлә; б) иярчен вакыт җөмлә; в) иярчен ия җөмлә.

**Тема 10. Диалогта тыныш билгеләре**

устный опрос , примерные вопросы:

1. Борылыш сүзендә а) аваз саны белән хәреф саны туры килми, ә әйтелеш белән язылыш туры килә; ә) аваз саны белән хәреф саны туры килә, ләкин әйтелеш белән язылыш туры килми; б) икесе дә туры килә; в) икесе дә туры килми. 2. Ясалу урыны буенча [һ] а) бугаз тартыгы; ә) кече тел тартыгы; б) тел уртасы тартыгы; в) йоткылык тартыгы. 3. Зурай сүзе а) кушма сүз; ә) тамыр сүз; б) ясалма сүз; в) кыскартылма сүз. 4. Имтиханны тапшыра алырмынмы дип борчыла Рәшидә. Бу җөмләдә борчыла сүзен кайсы фразеологизм белән алыштырып була? а) чыраен сыта; ә) ут йота; б) тәлинкә тота; в) кул кушырып утыра. 5. Тарихи сүзе а) нисби сыйфат; ә) охшату-чагыштыру рәвеше; б) күләм-чама рәвеше; в) асыл сыйфат. 6. Чикләүче кисәкчәләр генә кергән рәтне күрсәтегез. а) гына, генә, кына, кенә; ә) чалт, җете, иң, дөм; б) бит, ич, ла, лабаса; в) да, дә, ук, үк. 7. Тиңдәш кисәкләрдән соң килгән гомумиләштерүче сүз алдыннан кайсы тыныш билгесе куела? а) нокталы өтер; ә) ике нокта; б) сызык; в) өтер. 8. Җөмләнең иясе дә, хәбәре дә сан белән белдерелсә а) ике арага сызык куела; ә) алар бер-берсеннән өтер белән аерылалар; б) алар арасында ике нокта куела; в) бернинди дә тыныш билгесе куелмый. 9. Максат хәле кергән җөмләне табыгыз. а) Бүреген артка чөя төшеп, маңгаена бәреп чыккан тирне сөртеп алды Нургаяз. (Р.М.) ә) Аларны урманга нарат күркәсе җыярга алып кергәлиләр иде. (М.М.) б) Әллә кече яштән апасы тирәсендә кайнашканга, кыз кыю булып үсте. (С.С.) в) Яшь булуына карамастан, ул эшләрнең үзәгендә әлеге дә баягы Миңсылу бөтерелер иде. (М.Х.) 10. Бу нинди җөмлә? Нуриәсма аның чагуын көтте, ләкин корт чакмады. а) аерымланган хәлле гади җөмлә; ә) тиңдәш кисәкле гади җөмлә; б) тезмә кушма җөмлә; в) иярченле кушма җөмлә.

**Тема 11. Тыныш билгеләрен өйрәнү һәм гамәли куллана белү күнекмәләре булдыру**

устный опрос , примерные вопросы:

1. [?] (һәмзә) авазы булган сүзне күрсәтегез. а) компьютер; ә) мәкаль; б) берьюлы; в) мәсьәлә. 2. Кайсы җөмләдә сингармонизмның рәт гармониясенә буйсынмаган сүз бар? а) Үтә икән, китә икән Гомер дигәнең агып... ә) Җитә икән яшәү чоры Кадерсезләргә калып. б) Беркем килми, беркем китми, Һичкем белми хәлеңне. в) Берьялгызың үткәрәсең Шулай картлык мәлеңне (Ш.Җиһангирова). 3. Фонетик ысул белән ясалган сүзләрдән торган төркемне күрсәтегез. а) авылдаш, укучы, көйләгеч, бүлмә, ятак; ә) эреле-ваклы, тимгел-тимгел, ярты-йорты, аклы-каралы; б) әҗәт, игелек, бәләкәй, әмәл, әрәм, ачы; в) вуз, НАТО, партҗыелыш, комбиазык, ташбака. 4. Фразеологик әйтелмә кайсы рәттә бирелгән? а) эссе табада пешерә; ә) эссе табада кыздыра; б) эссе табага бастыра; в) дөрес җавап бирелмәгән. 5. Кайсы рәттә җырлашканнар сүзендәге кушымчалар ялгану тәртибе дөрес бирелгән? а) ясагыч, модальлек, бәйләгеч, модальлек; ә) ясагыч, модальлек, модальлек, бәйләгеч; б) ясагыч, модальлек, бәйләгеч, бәйләгеч; в) ясагыч, ясагыч, модальлек, бәйләгеч. 6. Кушымчалар сүзенең нигезен дөрес күрсәткән рәтне табыгыз. а) куш -; ә) кушым-; б) кушымча-; в) кушымчалар. 7. Түбәндәге фикерләрнең кайсысы дөрес? а) саннардан башка сүз төркемнәре ясалмый; ә) саннар башка сүз төркемнәреннән ясалмый; б) саннар башка сүз төркемнәреннән ясала; в) саннар җөмлә кисәге булып килми. 8. Кыргыч, кадак, көрәк. Бу сүзләрнең тамыры нинди сүз төркеменә карый. а) исем; ә) фигыль; б) сыйфат; в) рәвеш. 9. Җөмләнең төрен билгеләгез. Язмыш сине карурманнарда адаштырса, кояшка карап, юл сайла. (Ф.Я.) а) аерымланган рәвеш хәле белән катлауландырылган гади җөмлә; ә) аерымланган шарт хәле белән катлауландырылган кушма җөмлә; б) аерымланган шарт хәле һәм аерымланган рәвеш хәле белән катлауландырылган гади җөмлә; в) иярчен шарт җөмләле кушма җөмлә. 10. Иясе дә, хәбәре дә исем белән белдерелгән мәкальне күрсәтергә. а) Ике икең ? дүрт; ә) Уку ? энә белән кое казу; б) Алу күрке ? бирү; в) Үпкә - дошман, акыл ? дус.

**Тема 12. Тыныш билгеләре куюның аерым очраклары**

устный опрос , примерные вопросы:

1. [о] авазын тасвирлаган билгеләмәне күрсәтегез. а) арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшкән кыска аваз; ә) алгы рәт, югары күтәрелешле, иренләшкән озын аваз; б) арткы рәт, югары күтәрелешле, иренләшкән озын аваз; в) арткы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшкән кыска аваз. 2. Сүзчән сүзе кайсы орфографик принцип нигезендә язылган? а) фонетик; ә) морфологик; б) тарихи-традицион; в) график. 3. Угры малы каракка хәләл мәкалендә нинди сүзләр кулланылган? а) капма-каршы мәгънәле сүзләр; ә) мәгънәдәш сүзләр; б) аваздаш сүзләр; в) тамырдаш сүзләр. 4. Тезмә сүзне күрсәтегез. а) җил[...]давыл; ә) кып[...]кызыл; б) туз[...]баш; в) бал[...]корты. 5. Фразеологизмның мәгънәсен табыгыз: тел белән кош тоту - а) мактану; ә) каршы әйтү; б) гайбәт сөйләү; в) сөйләшмәү. 6. Керем-чыгым, аң-белем кебек сүзләр нинди ысул белән ясалганнар? а) бер сүз төркеменнән икенчесенә күчү; ә) сүз ясагыч кушымча ялгану; б) сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү; в) сүзләр кушылу. 7. Агач югарыга, җимеш түбәнгә омтыла (М. Хәсәнов) җөмләсендәге рәвешләрнең төркемчәсен күрсәтегез. а) саф рәвешләр; ә) күләм-чама рәвешләре; б) урын рәвешләре; в) вакыт рәвешләре. 8. Аерып билгеләнгән сүз кайсы сүз төркеменә карый? Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә, Аһ! Оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә (Г.Тукай). а) кисәкчә; ә) ымлык; б) аваз ияртеме; в) бәйлек. 9. Аерып бирелгән сүзтезмәнең төрен билгеләгез. Акыллы киңәш ? яртылаш кимегән эш(Ш.Галиев). а) фигыльле сыйфат сүзтезмә; ә) рәвешле фигыль сүзтезмә; б) сыйфатлы фигыль сүзтезмә; в) рәвешле сыйфат сүзтезмә. 10. Җөмләнең төрен билгеләгез. Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза(җыр). а) иярченле кушма җөмлә; ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә; а) тезем; в) гади җөмлә.

**Тема 13. Йомгаклау**

устный опрос , примерные вопросы:

I. Теоретик бирем. Татар телендә сүз төркеме буларак исем һәм аның ясалыш үзенчәлекләре. II. Гамәли бирем. Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан вә юлны тапмый калмый һәр адашкан(Г.Тукай). 1. Тыныш билгеләрен куеп, җөмләгә синтаксик анализ ясарга, схемасын сызарга, төрен билгеләргә. 2. Юлны сүзенә фонетик анализ ясагыз. 3. Һәрбер сүзен төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерегез. 4. Ыңгырашкан, вә, һәр сүзләренә морфологик анализ ясагыз.

**Итоговая форма контроля**

зачет

Примерные вопросы к зачету:

Орфоэпия фәне. Аны өйрәнүнең әһәмияте.

Татар телендә гарәп-фарсы алынмалары.

Орфоэпиянең кыен очраклары.

-да/-дә; -та/-тә кушымчаларының, да, дә, та, тә кисәкчәләренең һәм теркәгечләренең дөрес язылышы.

Орфография фәне. Аны өйрәнүнең әһәмияте.

Кереш сүзләр янында кирәкле тыныш билгеләрен куеп языгыз.

Татарларда язу тарихы.

Хәзерге татар әдәби теленең барлыкка килү тарихы.

Орфографик принциплар.

Сүзләрне морфологик принципка нигезләнеп язу.

Аерымланган хәлләр янында кирәкле тыныш билгеләре куеп языгыз.

Татар телендә е, ё, ю, я хәрефләренең дөрес язылышы.

Сүзләрне тарихи-традицион принципка нигезләнеп язу.

Татар телендә е, ё, ю, я хәрефләре белдергән авазлар. Бу хәрефләрнең сүз төрләнешендәге роле.

[w] авазының язуда бирелеше.

ь һәм ъ билгеләренең дөрес язылышы.

"Һәмзә" авазының язуда бирелеше.

Е, й, ж, ю, я хәрефләрен дөрес язу мәсьәләләре.

Баш хәрефне дөрес язу очраклары

Й хәрефенә беткән сүзләргә кушымчалар ялгану очраклары.

Ия белән хәбәр арасында сызык куелу очраклары.

Сүзләрне юлдан юлга күчерү.

Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре

Татар телендә рус-европа алынмалары.

Эндәш сүзләр янында тыныш билгеләре.

Кереш сүзләр янында тыныш билгеләре.

Аныклагычлар янында тыныш билгеләре.

Парлы сүзләр орфографиясе.

Сызык куелу очраклары

Тезмә сүзләр орфографиясе.

Ике нокта куелу очраклары.

Кыскартылма сүзләр орфографиясе.

Нокта куелу очраклары

Инфинитивның дөрес язылышы.

Нокталы өтер куелу очраклары.

Ялгызлык исемнәрнең дөрес язылышы.

Җәяләр куелу очраклары

О,ө, ы, э хәрефләренең дөрес язылышы.

Туры сөйләмдә тыныш билгеләре.

Сузык аваз хәрефләренең язылышы.

Сүз кисәкләрен юлдан-юлга күчерү.

Ымлыклар янында тыныш билгеләре.

Гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләре.

Аерымланган иярчен кисәкләре янында тыныш билгеләре.

Эйе, юк, ярый сүзләре янында тыныш билгеләре.

Татар телендә саннарның дөрес язылышы һәм кулланылышы.

Иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгесе.

**7.1. Основная литература:**


1. Павлов, А. В. Методологические проблемы современного гуманитарного познания [Электронный ресурс]: учеб. пособие / А.В. Павлов. - М.: ФЛИНТА, 2013. - 325 с. http://www.znanium.com/bookread.php?book=466244

2. Константинова, Л.А. Грамматика русского языка [Электронный ресурс]: Учеб.пособие / Л.А. Константинова, Н.Н. Гончарова, А.Н. Жукова; Под ред. Л.А. Константиновой. - М.: Флинта: Наука, 2011. - 256 с. - Режим доступа: // http://znanium.com/bookread.php?book=304030

3. Козырев, В. А. Современная языковая ситуация и речевая культура [Электронный ресурс]: учеб. пособие / В.А. Козырев, В.Д. Черняк. - М.: Флинта : Наука, 2012. - 184 с. Режим доступа: http://znanium.com/catalog.php?bookinfo=462837

4. Завалько, Н. А. Эффективность научно-образовательной деятельности в высшей школе [Электронный ресурс]: Монография / Н.А. Завалько. - 2-е изд., стереотип. - М.: Флинта, 2011. - 142 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=406102

5. Соснин, Н. В. Содержание обучения в компетентностной модели ВПО (К освоению ФГОС ВПО) [Электронный ресурс]: Монография / Н.В. Соснин. - Красноярск: Сибирский федеральный ун-т, 2011. - 242 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=443125


**7.2. Дополнительная литература:**


1.Сериков, В. В. Развитие личности в образовательном процессе: монография / В.В. Сериков. - М.: Логос, 2012. - 448 с. Режим доступа: http://znanium.com/catalog.php?bookinfo=469028

2. Соколков, Е. А. Проблемы поликультур и полиязычий в гуманитарном образовании [Электронный ресурс]: монография / Е.А. Соколков, Н.Е. Буланкина. - М.: Университетская книга; Логос, 2008. - 208 с. Режим доступа: http://znanium.com/bookread2.php?book=469068

3. Менеджмент качества образовательных процессов [Электронный ресурс]: Учебное пособие / Э.В. Минько, Л.В. Карташева и др.; Под ред. Э.В. Минько, М.А. Николаевой. - М.: Норма: НИЦ ИНФРА-М, 2013. - 400 с.- Режим доступа: http://znanium.com/bookread.php?book=400881


**7.3. Интернет-ресурсы:**

Википедия - http://ru.wikipedia.ru

Знаниум - http://znanium.com/catalog.php?bookinfo=466458

Книги - http: // kitaphane/tatarstan.ru

Татар теле - http://www.tatartele.ru

Татарская электронная библиотека - http://www.kitap.net.ru/

Электронный ресурс - URL:http://libweb.kpfu.ru/ebooks/10-IFMK/10_163_A5kl-000724.pdf>.

Үзебез - http://uzebez.org/tag/tatar-tele/

**8. Материально-техническое обеспечение дисциплины(модуля)**

Освоение дисциплины "Практикум по орфографии и пунктуации татарского языка" предполагает использование следующего материально-технического обеспечения:

Мультимедийная аудитория, вместимостью более 60 человек. Мультимедийная аудитория состоит из интегрированных инженерных систем с единой системой управления, оснащенная современными средствами воспроизведения и визуализации любой видео и аудио информации, получения и передачи электронных документов. Типовая комплектация мультимедийной аудитории состоит из: мультимедийного проектора, автоматизированного проекционного экрана, акустической системы, а также интерактивной трибуны преподавателя, включающей тач-скрин монитор с диагональю не менее 22 дюймов, персональный компьютер (с техническими характеристиками не ниже Intel Core i3-2100, DDR3 4096Mb, 500Gb), конференц-микрофон, беспроводной микрофон, блок управления оборудованием, интерфейсы подключения: USB,audio, HDMI. Интерактивная трибуна преподавателя является ключевым элементом управления, объединяющим все устройства в единую систему, и служит полноценным рабочим местом преподавателя. Преподаватель имеет возможность легко управлять всей системой, не отходя от трибуны, что позволяет проводить лекции, практические занятия, презентации, вебинары, конференции и другие виды аудиторной нагрузки обучающихся в удобной и доступной для них форме с применением современных интерактивных средств обучения, в том числе с использованием в процессе обучения всех корпоративных ресурсов. Мультимедийная аудитория также оснащена широкополосным доступом в сеть интернет. Компьютерное оборудованием имеет соответствующее лицензионное программное обеспечение.

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе " БиблиоРоссика", доступ к которой предоставлен студентам. В ЭБС " БиблиоРоссика " представлены коллекции актуальной научной и учебной литературы по гуманитарным наукам, включающие в себя публикации ведущих российских издательств гуманитарной литературы, издания на английском языке ведущих американских и европейских издательств, а также редкие и малотиражные издания российских региональных вузов. ЭБС "БиблиоРоссика" обеспечивает широкий законный доступ к необходимым для образовательного процесса изданиям с использованием инновационных технологий и соответствует всем требованиям федеральных государственных образовательных стандартов высшего профессионального образования (ФГОС ВПО) нового поколения.

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе "ZNANIUM.COM", доступ к которой предоставлен студентам. ЭБС "ZNANIUM.COM" содержит произведения крупнейших российских учёных, руководителей государственных органов, преподавателей ведущих вузов страны, высококвалифицированных специалистов в различных сферах бизнеса. Фонд библиотеки сформирован с учетом всех изменений образовательных стандартов и включает учебники, учебные пособия, УМК, монографии, авторефераты, диссертации, энциклопедии, словари и справочники, законодательно-нормативные документы, специальные периодические издания и издания, выпускаемые издательствами вузов. В настоящее время ЭБС ZNANIUM.COM соответствует всем требованиям федеральных государственных образовательных стандартов высшего профессионального образования (ФГОС ВПО) нового поколения.

Компьютерный класс, оргтехника, теле- и аудиоаппаратура; доступ к сети Интернет (во время самостоятельной подготовки).

Программа составлена в соответствии с требованиями ФГОС ВПО и учебным планом по направлению 44.03.01 "Педагогическое образование" и профилю подготовки Родной (татарский) язык и литература .


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Автор(ы):
Хуснутдинов Д.Х. ____________________
"__" _________ 201 __ г.

Рецензент(ы):
Галиуллина Г.Р. ____________________
"__" _________ 201 __ г.